**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6014**
**01.11.2022**

Башкарма комитетның «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 3 октябрендәге 5192 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә ярдәм күрсәтү максатында, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2021 елның 9 декабрендәге 10/3 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 3 октябрендәге 5192 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә ярдәм күрсәтү чаралары турында»;

2) преамбулада «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән

булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 пунктта:

- беренче абзацта «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балалар» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучылар һәм тәрбияләнүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктчада «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларының» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) әлеге карарда каралган ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучылар санын даими мониторинглауны алып барырга»;

5) 4 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) әлеге карарда каралган ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән булган, мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләргә (балалар бакчаларына) йөрүче тәрбияләнүчеләр санын даими мониторинглауны алып барырга».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев